СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ**
**27 октябрь, 2025 ел**

**КАРАР**
**№ 4**

**Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының хокукый хәлен камилләштерү турында» 2015 елның 02 февралендәге 424 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 24 июнендәге 158-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының хокукый хәлен камилләштерү турында» 2015 елның 02 февралендәге 424 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3 бүлекнең 3.2.12 пунктында «составы һәм сроклары» сүзләрен «формалаштыру тәртибе, составы һәм сроклары һәм» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында: http// vysokaya-gora. tatarstan. ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов